РАСЛЫЙМ
Дәүләт бюджет оешмасы
«Идел» яшьләр үзәге директоры

_______________ С.А. Кадыйров
«26» _______июнь_______ 2026 ел

# XXVI «ИДЕЛЕМ АКЧАРЛАГЫ»
# ЯШЬ ЯЗУЧЫЛАР БӘЙГЕСЕНЕҢ НИГЕЗЛӘМӘСЕ

## 1. Гомуми нигезләр

1.1. Әлеге нигезләмә XXVI «Иделем акчарлагы» яшь язучылар бәйгесен (алга таба – Бәйге) оештыру һәм уздыру, Бәйгедә катнашу һәм Бәйге җиңүчеләрен ачыклау тәртибен билгели.

1.2. Бәйгене Дәүләт бюджет оешмасы «Идел» яшьләр үзәге беренче тапкыр 2000 елның 1 сентябреннән татар телендә иҗат итүче яшь язучылар, шагыйрьләр, драматурглар өчен үткәрә башлый. Ул традицион рәвештә ел саен уздырылып килә.

1.3. Бәйгене оештыручылар: Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрлыгы, Дәүләт бюджет оешмасы «Идел» яшьләр үзәге, Татар федераль милли-мәдәни автономиясе һәм Татарстан Республикасы Язучылар берлеге.

1.4. Бәйгенең мәгълүмати партнерлары: «Миллиард.Татар» интернет-басмасы, «Идел» яшьләр журналы.

## 2. Максат һәм бурычлар

2.1. Бәйгенең максаты – сәләтле яшь каләм ияләрен барлау, берләштерү, иҗатларын активлаштыру.

2.2. Бәйгенең бурычлары:

- яшь язучыларның иҗат мөмкинлекләрен арттыру, иҗади яктан үсәргә шартлар булдыру;
- иҗади һәм профессиональ бәйләнешләрне ныгыту;
- яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең игътибарын татар әдәбиятына юнәлтү һәм иҗатка кызыксыну уяту.

## 3. Бәйгене уздыру тәртибе һәм шартлары

3.1. Бәйгедә Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка төбәкләрендә, чит илләрдә яшәүче, татар телендә иҗат итүче яшь каләм ияләре катнаша ала.

3.2. Бәйге түбәндәге категория катнашучылар арасында үткәрелә:

- 14 яшьтән алып 18 яшькә кадәрге авторлар;
- 19 яшьтән алып 35 яшькә кадәрге авторлар.

3.3. Бәйге өч этапта үткәрелә:

**3.3.1. I этап – 2026 елның 30 нчы сентябренә кадәр** әдәби әсәрләрне кабул итү.

**3.3.2. II этап – 2026 елның 1 октябреннән 31 октябренә кадәр** сайлап алу туры. Жюри тарафыннан әдәби әсәрләрне тикшерү, бәяләү.

**3.3.3. III этап – 2026 елның ноябрь көннәрендә** йомгаклау өлеше: алдан төзелгән программа нигезендә жюри тарафыннан әсәрләре уңай бәяләнгән катнашучылар өчен иҗади мәктәп оештыру.

3.4. Бәйге түбәндәге номинацияләрдә үткәрелә:

- поэзия;
- проза;
- драма.

3.5. 2026 ел – Идел елгасы елына багышлап язылган поэзия, проза яки драма номинацияләрендә иң яхшы әсәр авторына бер махсус бүләк тапшырылачак.

3.6. Бәйгенең беренче этабына гаризалар https://forms.yandex.ru/u/6a159b4ae010db0d92b56b0f сылтамасы буенча 2026 елның 30 сентябренә, 23:59 сәгатькә кадәр кабул ителә.

3.7. Бәйгегә әсәр җибәрү белән катнашучы аны бастыруга һәм интернет-ресурсларга урнаштыруга ризалык бирә. Оештыручылар, автор һәм әсәрнең исемен күрсәтеп, автор ризалыгыннан башка, бәйгегә килгән эшләрне куллану мөмкинлегенә ия була (катнашучы 3 нче турга үтсә, җыентыкта бастыру өчен һ.б.).

3.8. Әсәрләрне бәйгегә җибәргән очракта, катнашучы бәйге шартлары белән килешә.

## 4. Бәйге эшләренә таләпләр һәм бәя бирү тәртибе

4.1. Кыска күләмле әсәрләрнең (шигырь, нәсер, парча һ.б.) саны **өчтән** дә ким булмавы шарт.

4.2. Катнашучы, әсәрләре белән бергә, электрон гариза формасын һәм хокук иясене ризалыгы  (Кушымта 1) тутырып җибәрергә тиеш.

4.3. Әсәрләр түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш: Times New Roman шрифты, 12 нче кегль, 1,5 лы интервал. **«Проза» номинациясендәге әсәрләрнең күләме 20 000 тамгадан артмаска тиеш. «Драма» номинациясенә күләме 35 000 тамгадан артмаган пьесалар кабул ителә.**

4.4. Бәйгедә автор үзе иҗат иткән әсәр белән генә катнаша ала.

4.5. Алдагы елларда Гран-прига ия булучылар җиңү яулаган номинациядә кабат катнаша алмый.

4.6. Бәйгедә бер үк әсәр белән икенче тапкыр катнашып булмый.

4.7. Башка бәйгеләрдә катнашкан әдәби эшләр кабул ителми.

4.8. Югарыда күрсәтелгән таләпләргә туры килмәгән әсәрләр бәйгедә каралмый.

4.9. Бәйгедә катнашучыларның әсәрләре мәртәбәле жюри тарафыннан бәяләнәчәк. **Гран-прига лаек булучылар һәм барлык номинацияләрдә беренче, икенче, өченче урыннар, кызыксындыру бүләге ияләре Иҗади**

**мәктәптә катнашучылар арасында билгеләнәчәк.** Жюри хөкеме буенча, Гран-при яки һәр номинациядә барлык призлы урыннар бирелмәскә дә мөмкин.

4.10. Бәйгенең нәтиҗәләре буенча иң яхшы әсәрләр «Иделем акчарлагы» әдәби җыентыгында урын алачак.

4.11. Бәйгедә катнашучыларга электрон сертификат җибәрелә.

## 5. Жюри

5.1. Жюри рәисе һәм әгъзалары оештыручылар тарафыннан билгеләнә.

## 6. Элемтә өчен контактлар

Дәүләт бюджет оешмасы «Идел» яшьләр үзәге (Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 58 йорт, 307 офис)

Телефон: +7 (843) 528-28-22

E-mail: mc-idel@yandex.ru

Кушымта 1

## Согласие правовладельца

С ПРАВИЛАМИ положения о конкурсе ознакомлен и согласен;

- СОГЛАСЕН на обработку оргкомитетом мероприятия указанных персональных данных (в соответствии с требованиями Федерального закона от 27 июля 2006 года № 152-ФЗ «О персональных данных»);
- СОГЛАСЕН, что оргкомитет конкурса не несет ответственности за претензии и иски, связанные с авторскими и смежными правами материалов, предоставляемых на конкурс;
- СОГЛАСЕН на передачу прав на дальнейшее использование работы и её фрагментов в информационных, научных, учебных или культурных целях (публикация в сборнике конкурса, на сайте организации, в СМИ и т.д.) без выплаты вознаграждения, но с обязательным указанием имени автора и источника заимствования (в соответствии с требованиями статьи 1274 Гражданского кодекса РФ);
- ПРИНИМАЮ ответственность за точность указанной информации.

________________________________________________

*(Ф.И.О. участника)*

____________________ ____________________

*Дата* *Подпись*